КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 20 май г.Казань № 479

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларында булучы (булган) Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында

Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән һәм Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән гражданнарның яшәвен һәм туклануын оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территорияләрендә даими яшәүче, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы территориясеннән мәҗбүри киткән, Россия Федерациясе территориясенә ашыгыч рәвештә массакүләм тәртиптә килгән

һәм Татарстан Республикасында вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларында булучы (булган) Россия Федерациясе, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны урнаштыруга һәм тукландыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) өчен оешмаларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фондыннан субсидия бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Бу карар (Тәртипнең 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 17 пунктындагы икенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер–министры А.В.Песошин